Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы башкарма комитеты

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
31.01.2023 ел №9

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселокта җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә,Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогыбашкарма комитеты карар бирә:

1. 2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 7793,48 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымталар нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитетының 28.01.2022 ел, № 5 карары;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Җәлилшәһәртибындагыпоселогы
башкарма комитеты җитәкчесе И.Ф. Галлямов

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлилшәһәртибындагыпоселогы
башкарма комитеты җитәкчесенең
2023 елның 30 гыйнвар
9 номерлы карарына 1 кушымта

2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4840,47 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1448,65 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1504,36 |
| Барлыгы | **7793,48** |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
башкарма комитеты җитәкчесенең
2023 елның 31 гыйнвар
9 номерлы карарына 2 кушымта

2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Кәфенләү | 1568,46 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3266,44 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1448,65 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1509,93 |
| Барлыгы | **7793,48** |